**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ОЛЫ АЧАСЫР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

2022 елның 2 сентябре №96

2021 елның 15 июлендәге 49 нчы номерлы Олы Ачасыр авыл җирлеге Советы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре»нә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 24 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Олы Ачасыр авыл җирлеге Советы Регламенты нигезендә, Олы Ачасыр авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. 2021 елның 15 июлендәге 49 нчы номерлы Олы Ачасыр авыл җирлеге Советы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре»нә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Йорт хайваннарын һәм кошларны карап тоту»ның IX бүлегендәге 15 пунктның икенче абзацында «терлекчелек продуктлары» сүзләрен «хайваннар продукциясе» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук мәгълүмат стендларында: Олы Ачасыр авылы, Үзәк урамы, 46 йорт (җирлек хакимияте бинасы), Олы Ачасыр авылы, Кооператив урамы, 26 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

3. Бу карар 2023 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

**Олы Ачасыр авыл җирлеге**
**башлыгы урынбасары, Совет рәисе** **М.Г. Гатиятуллин**